Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№32 (83)

17 октябрь 2013 ел

# Туган тел сагында!

Туган телләрне һәм мәдәниятләрне үстерүгә, киләчәк буынга тапшыруга бәйле мәсьәләләр турында фикер алышу, шулай ук бу юнәлештә алдынгы тәҗрибәне өйрәнү, тарату һәм гомумиләштерү ихтыяҗы уңаеннан Казан федераль университетының Филология һәм сәнгать институтында 16-19 октябрь көннәрендә «Туган телләрне һәм мәдәниятләрне саклау һәм үстерү» II халыкара фәнни-гамәли форум уза.

*Форум турында тулырак 2 биттә укыгыз*



## • Вакыйгалар әзеннән

**7-9 ОКТЯБРЬ** көннәрендә Амстердамда Informatics Europe Ассоциациясенең **ХАЛЫКАРА КОНФЕРЕНЦИЯСЕ УЗДЫ**. Биредә Европа университетларының информатика һәм компьютер фәне буенча белгечләр әзерли торган факультет һәм кафедра җитәкчеләре катнашты. 2013 елдан КФУ да Informatics Europe Ассоциациясе әгъзасы булып тора һәм быел беренче тапкыр әлеге конференциядә катнашты.

• • • •

9-12 октябрь көннәрендә Казанда бокс буенча дөнья чемпионы Айрат Хамматов призына турнир уздырылды. Татарстанны яклаучылар арасында КФУның Физик культура, спорт һәм тернәкләндерү медицинасы институты студентлары да бар иде. **АКИМ НӘБИУЛЛИН** 64 кг үлчәү авырлыгында **БЕРЕНЧЕ УРЫННЫ** яулап, **СПОРТ МАСТЕРЫ** исеменә лаек булды. Антон Зайцев исә 81 кг авырлыктагы спортчылар арасында – икенче. Җиңүчеләрне котлыйбыз!

• • • •

13 октябрьдә УНИКС концертлар залында **КЕЧЕ УНИВЕРСИТЕТ** тантаналы рәвештә **ЯҢА УКУ ЕЛЫН БАШЛАП ҖИБӘРДЕ**. Килгән кунакларны проект җитәкчесе В.Летяев һәм ТР Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе урынбасары А.Исаевалар тәбрикләде. «5 фән» исемле беренче лекциядә химия, физика, биология, астрономия һәм геология фәннәре буенча «студентлар» төрле экспериментлар ясап карадылар. Киләсе дәрес 29 октябрьдә булачак дип көтелә.

• • • •

14 октябрь көнне КФУда «Когерентлы оптика һәм Оптик спектроскопия» исемле **XVII БӨТЕН РОССИЯ ЯШЬЛӘРЕ ФӘННИ МӘКТӘБЕ ЭШЛИ БАШЛАДЫ**. Лекцияләр һәм секцион докладлар 16 октябрьгә кадәр дәвам итте. Иң яхшы эшләр авторларына кыйммәтле бүләкләр, грамоталар һәм үзләренең докладларын Journal of Physics: Conference Series чит тел басмасында бастыра алу мөмкинлеге бирелде.

• • • •

Шул ук көндә Педагогика һәм психология институтында **«БАЛАНЫҢ МӘГЪЛҮМАТИ КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫГЫН ТӘЭМИН ИТҮДӘ ПСИХОЛОГИК-ПЕДАГОГИК ШАРТЛАР»** исемле түгәрәк өстәл узды. Чара барышында катнашучылар темага кагылышлы берничә видеоязма, шул исәптән бүгенге көндә балаларга күрсәтелә торган мультипликацион фильмнарны да карадылар һәм, шуларга нигезләнеп, актуаль булган мәсьәләләрне чишү юлларын эзләделәр.

• • • •

**16 ОКТЯБРЬ** көнне **РЕКТОРАТНЫҢ ЧИРАТТАГЫ УТЫРЫШЫ БУЛДЫ**. Аны Фәнни эшчәнлек буенча проректор **Д.НУРГАЛИЕВ** алып барды. Иң элек проректор контроль йөкләмләр үтәлеше һәм атна дәвамында үткәреләчәк чаралар турында сөйләде. Алга таба Халыкара бәйләнешләр институтының исемен Халыкара бәйләнешләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институтына алыштыру турында әлеге структур бүлек директоры **Р.ХӘЙРЕТДИНОВ**, Филология һәм сәнгать институты исемен Филология һәм халыкара бәйләнешләр институтына алмаштыру турында **Р.ҖАМАЛЕТДИНОВ**, Педагогика һәм психология институтын Психология һәм белем бирү институтына әверелүе турында **А.КӘЛИМУЛЛИН** хәбәр итте. Үзгәрешләр ректорат вәкилләре тарафыннан хупланды. Мәгълүматлашыру һәм элемтә департаменты директоры **Д.БУРМИСТРОВ** университет порталын алга җибәрү, Webometrics рейтингы буенча күрсәткечләр һәм аларны тагын да күтәрүгә юнәлдерелгән идеяләр тәкъдим итте. «Иң мөһиме: сайтка студентларның игътибарын җәлеп итәргә һәм аның структурасын кулланучылар өчен яраклаштырырга кирәк», – диде **М.САФИУЛЛИН**. Медиа Үзәк директоры **И.КӘРИМОВ** телевидение югары мәктәбен булдыру идеясен тәкъдим итте. Бу мәсьәләне ректорат вәкилләре шулай ук хуплады.

• • • •

Шулай ук кичә **КФУ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫНЫҢ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ ҮТТЕ.** Көн тәртибенә куелган мәсьәләләр буенча Гыйльми Советка өстәмә сайлаулар булды. КФУның юл картасы каралды. Уку йортының Уставына, коллектив килешүенә кертелгән үзгәрешләр турындаа мәгълүмат бирелде.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*

• Чара

# Туган тел һәм мәдәният сагында



Әңгәмәдәш **Динара МИННЕКАЕВА**

16-19 октябрь көннәрендә КФУның Филология һәм сәнгать институтында чираттагы масштаблы чара – «Туган телләрне һәм мәдәниятләрне саклау һәм үстерү» икенче халыкара фәнни-гамәли форум узa. Телләрне һәм мәдәниятләрне саклау республикабызда гына түгел, Россиядә, хәтта дөнья күләмендә дә бик зур проблема булып тора. Халыклар арасындагы дуслыкны ныгыту, милли кыйммәтләрне яшь буынга тапшыру өчен, җәмгыятьтә туган телгә, мәдәниятебезгә карата мөнәсәбәтне үзгәртергә кирәк. Чара шундый һәм аның белән бәйле башка бик күп мәсьәләләрне күтәреп, аларны чишү юллары буенча фикер алышуны күз алдында тота. Бу уңайдан без Филология һәм сәнгать институты директоры, профессор Рәдиф Рифкать улы Җамалетдинов белән әңгәмә кордык.

**– Рәдиф Рифкатович, университетта ана теле һәм мәдәнияте мәсьәләләре белән кызыксыну ни дәрәҗәдә, бу уңайдан нинди чаралар уза?**

– Соңгы елларда җәмгыятебездә ана телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү мәсьәләләренә карата төрле фикерләр, кайбер очракта бер-берсенә капма-каршы булган фикерләр яңгырый. Аларга җавап йөзеннән, безнең уку йорты базасында инде хәзер гадәти форма алган шактый гына чаралар үтеп тора: һәрелның октябрь уртасында мәртәбәле галимнәр катнашында фәнни-гамәли җыен, «Ана теле» түгәрәк өстәле (даими җитәкчеләре – Татарстан Дәүләт Советы депутаты, Комитет рәисе, күренекле шагыйрь, танылган җәмәгать эшлеклесе Разил Вәлиев, республика мәгариф министрының беренче урынбасары Данил Мостафин, КФУның кафедра мөдире, профессор Фираз Харисов), студентлар һәм мәктәп укучылары арасында татар теле, тәрҗемә өлкәләрендә олимпиадалар, февральдә – яшьләр (студент, аспирант һәм мәктәп укучылары) катнашында тел һәм мәдәният (лингвокультурология) мәсьәләләренә багышланган конференция, апрель ахырында – ана теле һәм әдәбияты декадасы (аның кысаларында төрле олимпиадалар, викториналар, фәнни-гамәли җыеннар) гөрләп уза. Проблемалар конференция кысаларына гына сыймый башлагач, көз көне уздырыла торган чарабызны форум форматына күчердек. Быел ул шундый масштабта икенче мәртәбә үткәрелә.

**– Форумның географиясе дә зурайдымы?**

– Әлбәттә, Россия галимнәре белән бергә, форум эшендә чит илләрдән дә хезмәттәшләребез катнашачак. Барлыгы 500ләп галим безнең җыенybызда катнашу теләген белдерде. Алар арасында АКШ, Япония, Төркия, Германия, Бельгия, Азәрбайҗан, Казахстан, Үзбәкстан, Украина һ.б. илләрнең җәмәгать эшлеклеләре, галимнәре һәм аспирантлары да бар.

**– Форум кысаларында нинди чаралар үтәчәк һәм аларның төп үзенчәлекләре нидән гыйбарәт?**

– 17 октябрь көнне, форумның тантаналы ачылышыннан соң, пленар утырыш узачак. Анда галимнәребезнең берсеннән-берсе кызыклы, үзенчәлекле темаларга чыгышлары көтелә. Әйтик, немец галиме Бартоломэ Рут Германия югары уку йортларында, танылган төрек галиме Мостафа Онәр исә Төркия югары уку йортларында хәзерге татар әдәби телен укытуның торышы турында сөйләячәк. Россия Фәннәр академиясенең лингвистик тикшеренүләр институты директоры урынбасары Е.В.Головко (Санкт-Петербург) илебездә яшәүче халыкларның телләрен саклау һәм үстерү белән бәйле үз фикерләре белән уртаклашачак. Көннең икенче яртысында татар һәм рус телләре юнәлешләре буенча берничә түгәрәк өстәл, шулай ук халкыбызның танылган шагыйре, җәмәгать эшлеклесе, безнең элеккеге укучыбыз Равил Фәйзуллинга 70 яшь тулу уңаеннан тантаналы чара да узачак. С.В.Рахманиновның тууына 140 ел тулуга багышланган концерт та форум кунакларының күңеленә хуш киләр дип уйлыйбыз.




18 октябрь көнне алты халыкара, ике бөтенроссия конференциясе дистәләгән секцияләр кысаларында үз эшен дәвам итәчәк. Элекке елларда без күбрәк ана теле темасы буенча гына сөйләшкән булсак, быел әдәбият һәм мәдәният, сәнгать өлкәләрен дә алырга булдык. Безнең фикеребезчә, телне саклау һәм үстерүдә бу юнәлешләрнең һәркайсының роле искиткеч зур. Бары тик аларның барысына да тиешле игътибар бирелгәндә генә ана теле кыйммәтләрен киләсе буыннарга түкми-чәчми тапшыру миссиясен уңышлы башкара алачакбыз.

Конференцияләребез арасында барлык төрки дөньяга мәгълүм галимнәр, университетыбызның Шәрәфле профессорлары, үз вакытында безнең уку йортын тәмамлаган М.З.Зәкиевнең 85 еллык юбилее уңаеннан уздырыла торган һәм В.Х.Хаковның фәнни-методик мирасын өйрәнүгә (әлегә хәтле 4 ел рәттән «Хаков укулары» буларак үткәрелеп килде), шулай ук күренекле тюрколог, милләттәшебез Э.Р.Тенишевка багышланганнары аерым фәнни һәм тәрбияви әһәмияткә ия дип исәплибез. Киләчәктә дә, фәнни-теоретик тематика белән беррәттән, мондый аспектка да игътибарыбызны киметмәскә исәп.

Форум кысаларында шулай ук «Татарларга тылмачлар кирәк» республика олимпиадасы, рус телле студентлар өчен татар теленнән алтынчы республика күләмендә олимпиада узачак. Беренчесендә мәктәп укучылары үз көчләрен сынаса, икенчесендә Татарстанның барлык югары уку йортларыннан дип әйтерлек студентлар катнашачак.

**– Әңгәмәгез өчен рәхмәт, Рәдиф Рифкатович. Изге эшегездә зурдан-зур уңышлар телибез!**

• Яшьлек–яңарыш

# Сәхнәдә - беренче курслар!

**Динә МӨХТӘСИПОВА**

Уку йортыбызның горурланырлык традицияләре бар. Шуларның берсе – Беренче курслар бәйрәме. Шушы көннәрдә Алабуга институтында Яр Чаллы, Чистай һәм Алабуга студентларының сайлап алу туры узды.



Көз – беренче курс студентлары өчен аеруча мөһим ел фасылы. Алар беренче тапкыр мөстәкыйль рәвештә зур тормышка аяк басалар. «Университет» дигән зур йортта «яши башлыйлар». Анда кагыйдәләр дә, таләпләр дә башка. Ә бу бәйрәм – беренче курсларны университет тормышы белән таныштыру, үзара дуслаштыру өчен менә дигән мөмкинлек. Әйтергә кирәк, студентлар бик тату, моны залдагы җанатарларның күплеге, күтәренке кәефе дәлилләп торды. Һәр институтның чыгышы үзенчәлекле булды.



Беренче булып чыгыш ясаган Яр Чаллы институты студентлары тамашачылар һәм мәртәбәле жюри игътибарына беренче курс студентының институт эшчәнлеге белән ничек итеп танышуын күрсәтте. Студентлар җыр-биюгә, нәфис сүзгә оста икәнлекләрен дә исбатлады, хәтта «Беренче курслар» дигән КВН командасы да оешкан булып чыкты.

Икенче булып сәхнә тоткан Чистай институты студентлары да талантлардан гына тора. Алар да моңлы җырлары, дәртле биюләре белән сөендерде.

Соңгылар булып сәхнә түренә Алабугалылар күтәрелде. Быел Алабуга институтына 115 ел тула. Студентлар концерт номерлары аша шул теманы яктыртты. Шулай ук, Чыңгыз ханның тууына 385 ел тулуга багышлап, программа күрсәтелде. Җыр-биюдән тыш, мәртәбәле жюри көзге мода коллекциясен дә бәяләү бәхетенә ирешә.


Конкурста катнашучыларны сәламләргә КФУның социаль һәм тәрбия эшләре буенча проректор **Ариф Межведилов** та килде. «Мондый зур чараны әзерләүдә укытучыларның да өлеше тими калмагандыр. Сезгә аеруча рәхмәт. Вакыт узган саен, һәр беренче курслар буынының кабатланмас булуын аңлыйсың. Студентлар бик яхшы әзерләнгән. Ләкин шуны онытмагыз: уку беренче урында торырга тиеш», – диде проректор.

КФУ студентлары үзләренең укуда да өлгер, башка өлкәдә дә актив булулары белән аерылып тора. Быелгы студентлар моны тагын бер кат дәлилләде. Алар бу чыгышлары белән яшь буынның ни дәрәҗәдә актив булуын күрсәтте.

Шушы күркәм номерлар арасыннан сайлап алынган иң-иңнәр Казаныбызда узачак Беренче курслар бәйрәменең гала-концертында тамашачыларны сөендерәчәк.

*Институтларның матбугат үзәкләре ярдәме беләнәзерләнде.*

• Югалту



Казан университеты ректораты, Н.И.Лобачевский ис. Математика һәм механика институты дирекциясе һәм математик анализ кафедрасы физика-математика фәннәре докторы, ТР Фәннәр академиясенең әгъза-корреспонденты **ДАНИЯР ХӘМИТ** улы **МӨШТӘРИНЕҢ** 69 яшендә вафат булуы турында хәбәр итеп, якыннары һәм туганнарының кайгысын уртаклаша. Ул – бөтен гомерен Казан университеты белән бәйләгән шәхес. 1962 елда механика-математика факультетына укырга керә. Студент елларында ук математик журналларда фәнни мәкаләләр бастыра. Индивидуаль план буенча укып, Казан университетын вакытыннан алда кызыл дипломга тәмамлый. 1969 елда кандидатлык диссертациясен яклый һәм фән дөньясына кереп китә. Данияр Хәмит улы – бик күп дәреслекләр һәм методик эшләнмәләр авторы. Ул талантлы укучылар белән эшләүгә дә күп вакытын бирә иде. Республика күләмендә олимпиадалар уздыруга да зур өлеш кертте. Уку йорты коллективы Данияр Мөштәринең нәтиҗәле фәнни-педагогик эшчәнлеге алдында мәңге рәхмәтле.

• Галимнәребез

Филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы, Россия лингвистик фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы һәм президиум әгъзасы, Ататөрек исемендәге Төрек фәнни лингвистик җәмгыятенең мактаулы хакыйкый әгъзасы, ТДГПУның мактаулы профессоры, Татарстандагы көнчыгышны өйрәнүчеләр фәнни җәмгыятенең мактаулы президенты, Бөтендөнья тюркология ассоциациясе президиумы әгъзасы – бу исемнәр барысы да бер генә шәхеснеке бизи – яраткан остазыбыз Мирфатыйх Зәкиевич Зәкиевне.

# Милләт көзгесе

**Рауза АСЫЛГӘРӘЕВА**

*Безнең чорда тел галимнәре арасында дөньяга танылган фән эшлеклеләреннән берсе, әлбәттә, Мирфатыйх Зәки улы Зәкиев. Аны бер тармак буенча гына эшләүче коеп куйган галим дип әйтеп булмый. Ул – тәҗрибәле педагог-остаз да, тарихчы да, этно-эколог та, администратор-оештыручы да һәм актив җәмәгать эшлеклесе дә.*



Гади авыл малае бу фәнни биеклекләргә ничек менеп җитте, кайдан көч алды? Мирфатыйх Зәкиевич – җир кешесе, туган җире – аның илһам чыганагы, туган теле – аны алга әйдәүче, иҗатка, камиллеккә рухландыручы көч.

М.З.Зәкиевнең фәнни казанышлары Татарстан галимнәрендә генә түгел, Россия галимнәре даирәсендә дә горурлану хисләре уята. Гомер буе зур коллективларны җитәкләгән, фәнни хезмәтләре белән дөньякүләм танылган галим, академик М.Зәкиевнең биографиясе дә гаять бай һәм гыйбрәт алырлык.

Ул 1928 елның 14 августында Татарстан Республикасының Ютазы районы Зәйпе авылында туа. Кече яшьтән әтисез калуы аны балачактан ук тормышның кырыс сынауларына алдына китереп бастыра. Бөек Ватан сугышы еллары авырлыгын яшүсмергә үз җилкәсендә татырга туры килә. Мирфатыйх яшьтән үк авыл хуҗалыгындагы барлык эшләрдә дә катнаша, зур чыныгу ала. Аңа тимерче булып эшләргә дә туры килә. Тимер чыңы әле дә М.Зәкиевнең колагында чыңлыйдыр кебек. Ни дисәң дә, алтын куллы, көчле рухлы егеткә тимер дә чыдамаган, буйсынган, ул теләгән бизәк-орнамент рәвешенә кергән. Ул да, телгә килеп, «Үз бәхетеңнең тимерчесе бул!» дип әйткәндер төсле.

М.Зәкиев 1946 елда Казанга килә. Мәрмәр колонналы чал университетның ак баскычлары белемгә, фәнгә омтылган яшь егет өчен беренче биеклек була. М.З.Зәкиевнең педагогик эшчәнлеге шушы университет диварлары эчендә башлана. Аңа кадәр ул, бу уку йортын уңышлы тәмамлап, шунда ук аспирантурада белем ала һәм татар телендә хәбәр семантикасы һәм синтаксикасы буенча кандидатлык диссертациясен яклый, татар теле белеме фәнендә, береннеләрдән булып, югары уку йортлары өчен «Татар теле синтаксисы» курсын әзерли һәм әлеге өлкә белән бәйле беренче монографиясен бастырып чыгара.

Озак та үтми, аның тарафыннан «Татар теленең синтаксик төзелеше» исемле монография әзерләнеп, 1963 елда бу хезмәт докторлык диссертациясе итеп яклана. Университетта татар теле кафедрасы оештырылгач, аның мөдире итеп сайлана һәм бу вазифасында үзен оста җитәкче итеп күрсәтә.

Тел өлкәсендәге саллы хезмәтләре, дәреслекләре, Казан дәүләт университетында, Казан дәүләт педагогика университетында, Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшләгән елларында 70тән артык аспирантка җитәкчелек итүе, шуларның 20сенең фән докторы, профессор дәрәҗәсенә ирешүе, татар теле һәм этносы турындагы тарихи хезмәте («Татар халкы теленең барлыкка килүе»), 1980-1990 еллар арасында Татарстан Югары Советы депутаты һәм рәисе булуы шулар хакында сөйли.

90 нчы еллар башында М.З.Зәкиев бик актив рәвештә милләт язмышы турында уйлану, милләтне саклау һәм үстерү проблемалары белән шөгыльләнә башлый. Милләт язмышында иң әһәмиятле мәсьәлә — милли телне тергезү, саклау һәм үстерү икәнен яхшы күзаллап, ул 1992 елда кабул ителгән «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Законны эшкәртүдә һәм кабул итүдә, 1994 елда бу Законны гамәлгә кертү буенча «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы»н төзүдә башлап йөрүчеләрнең берсе булды.

М.З.Зәкиев 1994-99 елларда – Татарстан Министрлар кабинеты каршында тел Законын гамәлгә ашыру комитеты рәисенең (Премьер-министрның) урынбасары буларак хезмәт күрсәтте.

Аның тел белгече буларак таланты татар теленең өч томлык академик грамматикасын төзү кебек киң масштаблы проектны тормышка ашыруда аеруча ачык чагыла. Бу хезмәт Татарстан Республикасының фән һәм техника өлкәсендәге дәүләт бүләгенә лаек була.

Хәзер ул – Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының баш гыйльми хезмәткәре, Халыкара төрки академиясенең Татарстан бүлеге академигы-сәркатибе, Төрек тел җәмгыятенең шәрәфле академигы. М.З.Зәкиев 1035 фәнни хезмәт авторы, шуларның 90га якынын дәреслек, кулланма, монографияләр тәшкил итә.

Ул әле дә хезмәттә, тулы көченә эшли, ил эчендә, чит илләргә командировкаларга барып кайтырга да авырсынмый. Сәламәтлекне саклый белү иҗади эшне озак дәвам итүнең төп чарасы булуына чын күңелдән ышанып яши һәм башкаларга да шулай эшләргә киңәш итә.

Хезмәтенә күрә – хөрмәте, ди халык. Мирфатыйх Зәки улы Зәкиевнең хезмәтләренә хөкүмәтебез дә югары бәя бирде. Ул Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы орденнары һәм күп кенә медальләр белән бүләкләнде, Татарстан Республикасының фән һәм техника өлкәсендә Дәүләт премиясенә лаек булды. 1970 елда аңа Татарстанның, 1976 елда Россиянең атказанган фән эшлеклесе дигән мактаулы исемнәр бирелде.


Мөхтәрәм шәхес, дөньякүләм танылган галим, җәмәгать эшлеклесе, бүгенге көндә дә университетыбыз студентларына белем-тәрбия бирүче, укытучы-профессорлар коллективына матур үрнәк булып, фәнни үрләргә рухландырып торучы Мирфатыйх Зәкиевич Зәкиевне ихлас күңелдән олы юбилее белән котлыйбыз, аңа нык сәламәтлек, иҗат уңышлары телибез.

• Алар бездә укыган

# Бергә үткән яшьлек

**Әнвәр ШӘРИПОВ**, Яр Чаллы социаль-педагогик технологияләр һәм ресурслар институты

Безнең яшьлек еллары Равил Фәйзуллин белән бергә үтте. 1960-1965 елларда без аның белән КДУның татар теле һәм әдәбияты бүлегендә бер төркемдә укыдык. Әмма аның белән без гадәти сабакташлар гына түгел, ә якын дуслар да булып киттек. Ул дуслык, хәзер инде мин моны ныклы итеп әйтә алам, гомер буена сузылды.



Безнең танышлык абитуриент чактан ук башланды. Ул елларда хәтта абитуриентларны да, имтиханнар бирү чорына, университетның тулай торагына урнаштыралар иде. Миңа да, Казанга килү белән, Кызыл Позиция урамындагы 1нче тулай торактан урын бирделәр. Хәзер дә хәтеремдә, 64 нче бүлмәгә урнаштым. Бу минем өчен, моңа кадәр авылдан ерак китмичә яшәгән яшүсмер егет өчен, әр-яңа дөнья булды. Тизрәк кешеләр белән танышасы, сөйләшәсе-белешәсе килә. Безнең бүлмәдә татар теле һәм әдәбияты бүлегенә керүчеләр юк. Мин коридорга чыктым. Бер егет белән сөйләшеп киттек. Ул Кадыйр Сибгатуллин булып чыкты. Ул миңа: «Безнең бүлмәдә Балык бистәсе районыннан тагын берәү – Равил дә бар әле. Әйдә, таныштырам», – диде. Без кердек. Менә шунда мин беренче тапкыр Равил Фәйзуллинны күрдем. Без танышып-сөйләшеп киттек. Шунысы ачыкланды: безнең өчебезнең дә хыялы бер – укырга керү иде.

Һәм менә бәхет! Ур-ра! Без икебез дә укырга кердек! Шатлыгыбыз әчкә сыймады... Әмма безне, әле генә мәктәпне бетереп кергән студентларны, беренче курста кайда да булса берәр производствода эшләп укырга мәҗбүр иттеләр. Моның үз мантыйгы да бар иде: янәсе, бу бүлекне элегрәк тәмамлаган белгечләрнең күпчелеге республика һәм район газета-журналларында эшкә калган. Шундый хәлне булдырмас өчен, «яшел школьникларны» берәз гына булса да реаль тормыш белән таныштыру максаты күздә тотылган. Равил беренче курста башта бер оешмада тәэминат бүлеге белгече булып, аннан төзелештә эшләп укыды. Ә мин Казанның 40 нчы Төзелеш трестында маляр булып эшләдем, шул трестның тулай торагында яшәдем. Шулай итеп, без Равил белән беренче курс дәвамында, икебез ике җирдә эшләү сәбәпле, бик еш аралаша алмадык.

Икенче курска укырга килгәч, көз көне безне Арчамы, Әтнәме – кайсыдыр бер районга колхозга бәрәңге алышырга җибәрделәр. Менә шунда без Равил белән чын мәгънәсендә якыннан дуслашып киттек, аерылмас дусларга әйләндек. Безнең икебезне дә киләчәккә чиксез омтылыш, зур иҗади планнар, хыяллар берләштерә иде.

Колхоздан кайткач, Равил дә университетның 2 нче тулай торагына урнашты. Бер үк бүлмәгә туры килмәсәк тә, без аның белән гел бергә идек. Ул елны 1нче курска Гәрәй Рәхим, Рөстәм Мингалимовлар да укырга керде. Алар белән танышып киттек. Шулай итеп, тулай торакта киләчәктә «милләтебезнең каймагы» булачак яшь шагыйрьләрнең бер төркеме барлыкка килде. Аралашу-фикерләшү нәтиҗәсендә, алар берберсе белән үзара ярыша-ярыша иҗат итәргә тотындылар.

Ул елларда студентлар тормышы гөрләп торды. Университетның үзендә әдәбият-иҗат түгәрәге эшли, 6-7 метр озынлыгында «Әдәби сүз» исемле стена газетасы чыгарыла. Өстәвенә, атна саен диярлек, «Татарстан яшьләре» газетасы каршындагы әдәбият-иҗат берләшмәсе утырышлары, язучыларның Тукай клубында әдәби кичәләр үткәрелеп тора. Без аларның барысында да актив катнашабыз. Равил һәрвакыт аларның үзәгендә була, гел үзәктә кайный. Ул үзенең активлыгы, ярсу таланты белән башкалардан аерылып, аларны үзенә тартып, үзенә җәлеп итеп тора иде.

Тулай торакта яшәү (бер бүлмәдә дүрт кеше), шигърият белән «җенләнгән» яшь талантларга иҗат итү өчен, әлбәттә, уңайлы булмады. Ә Равил, иҗат өчен мөмкинлекне үзе булдырды: икенче курстан соң ул, тынычлап иҗат итәр өчен, аерым фатирга күчте, Казанның Тихогорская урамындагы 3 нче йортта бер бүлмә алып, шунда яши башлады.

Дүртенче курста укыган чакта, без Равил белән Казанда гына «бикләнеп ятмаска», ә зуррак шәһәрләргә – Мәскәү-Ленинградларга барып, алардагы мәдәният тормышы белән дә танышып кайтырга, дип план кордык. Стипендияләрне «кысып», газета-журналлардан килгән гонорарларны җыеп, беркадәр акча тупладык. Һәм кышкы сессиядән соң, 1964 елның гыйнвар ахырында, реактив самолетка утырып, Ленинградка очып киттек. Бу очыш Равилгә «Самолетта, биеклек – 8000 м» дигән шигырен язарга нигез булды. Ленинградтан без гаять зур тәэсирләр алып, рухи яктан баеп чыгып киттек, поезд белән Мәскәүгә юнәлдек. Ә Мәскәүдә без икеме-өчме көн генә тордык шикелле. Шуның белән безнең кышкы каникул вакытындагы сәяхәтебез тәмам булды.

Шушы сәяхәттән кайтканда ук, без алдагы көннәргә дә план корып куйдык: булдыра алган кадәр акча җыярга, кирәкле документларны әзерләргә дә, турист булып кайсы да булса берәр чит илгә барып кайтырга! Ә студент өчен бу планны тормышка ашыру зур кыюлык үрнәге иде. Әмма тырыша торгач, без бу максатка да ирештек. Икебез бергә булмаса да, бишенче курста укыр алдыннан, икебез дә чит илләргә турист булып барып кайттык: 1964 елның көзендә Равил Югославиягә, ә мин Польша белән Чехословакиягә сәяхәт кылып кайттык. Сәяхәт итү безнең дөньяга карашыбызны киңәйтте, бәя биреп бетерә алмаслык рухи азык бирде. Чит илдән кайткач, без бер-беребез белән тәэсирләрне уртаклаштык.

Университетны тәмамлап чыккач, без икебез ике юнәлештә эшли башладык. Равил шигърияткә мөкиббән булып яшәде, туктаусыз иҗат итте. Зур уңышларга иреште: халкыбызның олпат шагыйре булып танылды, олыолы исемнәр яулап алды. Ә мин фән өлкәсен сайладым. Аспирантурада укып, борынгы татар әдәбияты мәсьәләләре хакында фәнни хезмәтләр язу белән шөгыльләндем. Икебез ике өлкәдә эшләсәк тә, без үзара әчкерсез, ихлас дуслар булып калдык. Минем өчен Равил һәрвакыт ышанычлы дус булды. Тормыш юлында андый дустың-таянычың булу – ул үзе зур бер бәхет бит.

*Әйе, дускай,*
*Гомер язы безнең,*
*Чишмә моңы кебек,*
*Кабатланмас матур җыр иде.*
*Хөрмәт белән аны искә алыйк:*
*Гомер язы безнең бер иде.*

• Сәләткә сәбәп кирәк



# Икенче тапкыр кәләш!

Алинә САДЫЙКОВА

Син дә күрдеңме? Мин дә күрдем... Алар бик күп иде! Шәһәр үзәге, сәүдә йортлары буенча йөгереп йөрделәр! Тирә-юньдәгеләрне кияүгә чыгарга, өйләнергә өндәделәр. Туй күлмәкләре кигәннәр дисеңме? Сон, алар «Кәләшләр вальсы» проектында катнашучылар бит!

Дустым, син ни турында сүз барганын һаман аңлап бетермәдеңме? Шушы көннәрдә Пирамида күңел ачу үзәгендә бер ай дәвамында барган «Кәләшләр вальсы» проектының финалы узды. Шунысы куандыра: республика күләмендә узган чарада ике хезмәткәребез университет данын яклады. Газетабыз мөхәррире **Динара Миннекаева**, Идарә һәм территориаль үсеш институтының икътисади методология һәм тарих кафедрасы ассистенты һәм лаборанты **Алия Шиһабиева** үз гомерләрендә икенче тапкыр туй күлмәге киделәр. Визитка өлешендә Динара сәхнәгә безнең газетаны тотып чыкты.

Проектның максаты да шул: гаилә тормышын пропагандалау, сизелми дә узып киткән иң бәхетле мизгелләрне тагын бер кат искә төшерергә ярдәм итү. Проектта бары тик кияүдәге гүзәл затлар гына катнаша ала, ләкин кайчан кияүгә чыккан булу мөһим түгел. Хәтта берничә ел рәттән катнашучылар да бар икән. Кастинг үткәч, катнашучылар финалга әзерләнә башлый. Быел проектка биш ел тулды. Алдагы еллардагы ке-



▪ Кәләшләр Бауман урамын да гөрләтте.

бек үк, юбилей елында да тантаналы чара махсус тематикага багышланган иде. Тамашачылар, вакыт машинасына утырып, проектның биш ел дәвамындагы эшчәнлеге нәтиҗәсе белән таныша алды. Ханбикәләр сыман киенгән кызлар безне антик чорга, урта гасырга алып кайтты. Шулай ук без «великосветские дамы», «богемные дивы»лар белән таныша алдык. Кәләшләр бар яктан да килгән: моңлы итеп җырлыйлар, дәртле итеп биилэр, кул эшләренә дә оста үзләре, кайберләре хәтта костюмнарны да үз куллары белән әзерләгән.

«*Проектта катнашып, мин үзем өчен бөтенләй икенче бер дөнья ачтым, яңа дуслар таптым. Оештыручылар безнең өчен бик күп мастер-класслар үткәрде. Без дөрес итеп бизәнү әйберләре, кием-салымнар сайларга, чәчәк бәйләмнәре ясарга өйрәндек, гаилә психологлары белән очраштык, спорт белән шөгыльләнергә дә вакыт таптык. Мондый проектларда катнашу камилләшү өчен мөмкинлек бирә. Вакытны да дөрес бүлә башлыйсың*», – дип, фикерләре белән уртаклашты Динара. Проектның Интернеттагы официаль төркеменә керсәң дә, башка катнашучыларның шундый фикерләрен укырга мөмкин.

«Кәләшләр вальсы» проектында җиңүче дә, җиңелүче дә юк. Аларның һәркайсы – җиңүче! Оештыручылар әйтүенчә, аларның саны елданел арта. Димәк, бәхетле гаиләләр саны да күбәя дигән сүз. Бу сихри дөньяга эләгәсең, туй көнеңне тагын бер мәртәбә искә төшерәсең килсә, рәхим ит. Үзеңнең иң бәхетле кәләш икәнеңне исбатла!

• Аклы-каралы дөнья

# Ә син электрон китап укыйсыңмы?

**Раил САДРЕТДИНОВ,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

XXI гасыр, мөгаен, югары технологияләр һәм мәгълүмати шартлау заманы булып тарихка кереп калыр. Вакыт шулкадәр тиз чаба ки, хәтта 10 ел элек кенә һәрбер кешедә кәрәзле телефон, үз компьютеры булу хыялда гына иде әле.

Яңа технологияләр тормышыбызга үтеп керүгә, искеләрен бик тиз генә алыштыра да башлады. Сүзем электрон китаплар турында. Хәзер кулына басма китап тотып укучылар сирәгәйгәннән-сирәгәя бара. Бөтендөнья пәрәвез челтәрендә китапларның ниндиләре генә юк. Хәтта сирәкләрен дә очратырга була. Укып кына өлгер! Онлай режимда укып утырасың килмәсә, компьютерыңа яки телефоныңа да күчерергә мөмкин. Кайчан вакытың була – шунда ачып укый аласың.

2012 елның сентябрь аеннан КФУ студентларына «Книгафонд» электрон китапханә челтәренә бушлай керү карталарын тараттылар. Курс эшләрен язганда, әдәбият исемлегенең 50% шул челтәрдән булырга тиешлеген искәрттеләр. Бүген бу электрон китапханә челтәрендә 154423 китап теркәлгән. Алар һәр көн саен диярлек артып торалар. Бу системаның уңай яклары да, тискәре яклары да юк түгел. Бер яктан ул – бушка, китапханәгә барып кайту өчен юл чыгымнарына акча әрәм итәсе түгел. Вакытны да юкка әрәм итмибез – интернетка керү мөмкинлеге булган җирдә укый алабыз. Китапханәдә өстәл артында утырырга да кирәкми – теләсәң, ятып та укый аласың. Тик икенче яктан, болай да какшаган сәламәтлегебезгә зыяны да юк түгел. Мондый китапны укыганда, күзләр тиз арый, баш мие барлык мәгълүматны да аңлы рәвештә кабул итә алмый. Студентларыбыз электрон китапханә челтәрләреннән, китаплардан еш файдалана микән? Уңай һәм тискәре якларын нидә күрәләр? Яшьтәшләремнең фикерләрен белешергә булдым.

**АЛСУ ЗИННУРОВА, Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты:** «Электрон китапларны кулланмыйм. Яхшыдыр инде ул, кирәк вакытта карап укый аласың. Тискәре ягын әйтә алмыйм».

**НУРСИЯ МИНЗИНА, Филология һәм сәнгать институты:** «Кайвакыт файдаланырга туры килә. Бигрәк тә татар теленнән кагыйдәләр кулланганда, әсәрләргә мисаллар эзләгәндә яисә берәр мәгълүмат, кызыклы фактлар эзләгәндә электрон китапханәдән файдаланам. Уңай якларына килгәндә, мәгълүматны бик тиз табып була, уңайлы, җайлы, бер төймәгә басасың һәм «китапханә»гә эләгәсең. Ләкин электрон китапханәдән генә файдалану басма китапны юкка чыгарырга мөмкин. Әдәби әсәрләргә карата мәхәббәтебез сүнә, китапның бөтенләй кирәге калмый булып чыга түгелме? Мин китап укырга бик яратам, бигрәк тә кичләрен, ял көннәрендә, шуны укып кайчак йоклап киткәнеңне сизми дә каласың».

**АЛЬБИНА ВӘЛИЕВА, Филология һәм сәнгать институты:** «Китапханәләргә хәзерге яшьләр бик сирәк йөри, чөнки интернеттан материал табу җиңелрәк, вакыт та күп кирәкми. Кызганычка каршы, бүген без китапның кадерен оныта барабыз. Кулга да бик сирәк алабыз. Заман технологияләре алга киткән саен, кеше ялкаулана бара».

**ГӨЛЧӘЧӘК ХӨСНУЛЛИНА, Филология һәм сәнгать институты:** «Мин үзем электрон китапханәдән файдаланам, бу бик уңайлы әйбер. Тиз арада кирәк булган материалны табасың. Әмма курс эшләре кебек саллы, зур хезмәтләр, фәнни эшләр башкарганда, зур роман, повестьлар укыганда авырлык сизелә, чөнки сәгатьләр буе экраннан уку күзгә дә зыян сала. Ни генә дисәң дә, кулга тотып, китап укуга җитми инде».

**ИЛМИР ВӘЛИЕВ, Н.И.Лобачевский исемендәге Математика һәм механика институты:** «Электрон китапханәдән актив файдаланам дип әйтә алмыйм. Басма һәм электрон китапларга бертигез карыйм. Икесенең дә уңай һәм тискәре яклары бар. Шуңа күрә берсенә дә өстенлек бирмичә, мин алтын урталыкны табарга тырышам».

**ГҮЗӘЛИЯ ГЫЙНИЯТУЛЛИНА, Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты:** «Электрон китапханә челтәрен кулланмыйм, чын китапны үз кулыма тотып уку минем өчен яхшырак. Китапның тәмен тоеп, анда барган вакыйгаларга төшенеп укый аласың. Ә электрон китап, минемчә, сәламәтлеккә зарар гына китерә».

Иптәшләремнең фикерләре белән килешәм. Дөресен генә әйткәндә, кулыңа басма китап тотып укуны берни дә алыштыра алмый.

# Иң бөек көн

15 октябрь көнне бөтен дөнья мөселманнары иң зур дини бәйрәмнәренең берсе булган Корбан гаетен билгеләп үтте.

**Илмир ВӘЛИЕВ,**
Математика һәм механика институты

Корбан гаете мөселман календаре буенча соңгы – Зөлхиҗә аеның унынчы көненә туры килә. Гает көннәрендә барча мөселманнар мәчеткә намаз укырга баралар, бер-берсенең хәлен белешәләр, вафат булган ата-аналары, әби-бабалары, туган-тумачалары рухына багышлап дога кылалар, хәер бирәләр. Бәйрәм табыннарына дин әһелләре һәм башка кунаклар чакырыла. Коръән укыла, изгелеккә өндәп, вәгазьләр сөйләнә. Әлеге бәйрәм бигрәк тә авыруларга, олы буын вәкилләренә, ятимнәр һәм мохтаҗларга битараф калмаска, аларга игътибар һәм ихтирам күрсәтергә чакыра.

Күп кешеләр Гает көнне Аллаһы ризалыгы өчен корбан чала. Корбан чалу – Аллаһка якынаю дигәнне аңлата, шуңа да һәрбер мөселман бу изге гамәлне дөрес итеп, барлык нечкәлекләрен исәпкә алып башкарырга тырыша.

Корбан чалуның да үз тарихы булган. Риваятьләргә күз салсак, Аллаһ Тәгалә ике пәйгамбәрне зур сынауга дучар иткән. Ибраһим пәйгамбәрдән улы Исмәгыйль пәйгамбәрне корбан китерергә сораган. Моны икесе дә тыныч кабул итеп, Ибраһим пәйгамбәр улын корбан китерергә әзерләнгән. Тик Ходай аларны бу эштән азат иткән, корбан итәр өчен, Исмәгыйль пәйгамбәр урынына бер сарык җибәргән. Шуннан башлап, мөселманнар ел саен корбан чалалар. Бу корбанның бер өлеше мохтаҗларга өләшенергә, икенче өлеше белән табын корып, аш уздырылырга, өченче өлеше үз гаиләңә калырга тиеш.

Корбан бәйрәме республикабыздагы халыкара дуслыкны, бердәм хезмәттәшлекне ныгыта, мөселман өммәтен берләштерүгә ярдәм итә. Пәйгамбәребез (с.г.в) бер хәдисендә әйтә: «Аллаһы каршында көннәрнең иң бөеге – Корбан бәйрәменең беренче көне», – ди. Бүген бәйрәмнең өченче көне. Изге гамәлләр кылып, бер-беребезгә мәрхәмәтле, игътибарлы булыйк. Аллаһы Тәгаләнең иксез-чиксез рәхмәтләренә барчабызга да ирешергә, гомерләребезне хәерле итеп үткәрергә насыйп итсен! Ил-көннәребезгә тынычлык-иминлек, бәрәкәт бирсен иде.

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.